МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

______03.08.2021_________ Казан шәһәре №_______295_______

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 августындагы 277 номерлы боерыгы белән расланган Кара металл, төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү хакында

**Боерык бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 августындагы 277 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2014 елның 8 августындагы 289 номерлы, 2015 елның 19 мартындагы 134 номерлы, 2015 елның 3 июлендәге 317 номерлы, 2016 елның 16 мартындагы 70 номерлы, 2016 елның 2 июнендәге 176 номерлы, 2017 елның 2 июнендәге 172 номерлы, 2018 елның 19 апрелендәге 172 номерлы; 2018 елның 13 июлендәге 335 номерлы, 2019 елның 29 октябрендәге 545 номерлы, 2020 елның 9 сентябрендәге 405 номерлы, 2021 елның 5 февралендәге 42 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Кара металл, төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертеп, аны кушымтада бирелә торган яңа редакциядә бәян итәргә.
2. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары Н.В.Кондратовка йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Премьер-министры урынбасары –**
**Министр** **М.Р.Шаһиәхмәтов**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгының
26.08.2013 № 277 боерыгы
белән расланды (Татарстан
Республикасы Икътисад
министрлыгының
03.08.2021 № 295
боерыгы редакциясендә)

Кара металл, төсле металл ватыклары әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Кара металл, төсле металл ватыклары әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Регламент) кара металл, төсле металл ватыклары әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр: юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар (алга таба – лицензия алырга теләүче зат, лицензиат), гражданнар.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Министрлыкның урнашкан урыны: Казан шәһәре, Мәскәү урамы, 55.

Министрлыкның эш графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, дүшәмбе-пәнҗешәмбе 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр, җомга 9.00 сәгатьтән 16.45 сәгатькә кадәр, төшке аш: 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Гаризалар кабул итү графигы: һәр көнне, шимбә һәм якшәмбе көннәреннән тыш, Министрлыкның эш сәгатьләрендә.

Җәмәгать транспорты белән «Г.Камал исемендәге театр» яки «Париж коммунасы урамы» тукталышына кадәр килергә кирәк:

- № 1, 2, 6, 10, 10а, 23, 30, 31, 35, 35а, 37, 47, 53, 54, 56, 63, 68, 71,72, 74, 91 автобуслар;
- № 3, 5, 7 троллейбуслар.

Кертү пропуск һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ ярдәмендә.

1.3.2. Министрлыкта Лицензияләү бүлегенең (алга таба – бүлек) белешмә телефоннары: 524-91-48, 524-91-49, 524-90-22.

1.3.3. Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайты адресы: http://mert.tatarstan.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында, шулай ук бүлек урнашкан урын һәм аның эш графигы турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләрдәге (алга таба – күпфункцияле үзәк) бүлмәләрдә урнаштырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендлары аша;

2) «Интернет» челтәре аша:

«Интернет» челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында (http://mert.tatarstan.ru).

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат стендларында һәм Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчасындагы) белешмәләрне үз эченә ала.

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (http://uslugi.tatar.ru/) (алга таба – Республика порталы);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында (https://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал);

3) Министрлыкка телдән (шәхсән яки телефон аша) мөрәҗәгать иткәндә;

4) Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә.

5) күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткәндә.

1.3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча консультация бирү түбәндәгеләрдә гамәлгә ашырыла:

1) күпфункцияле үзәктә – шәхсән яки телефон аша;

2) Республика порталының интерактив формасында;

3) Министрлыкта:

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яки телефон аша;

язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ форматында да) – почта аша кәгазьдә, электрон почта буенча электрон формада.

1.3.6. Министрлык урнашкан урын, аның белешмә телефоннары, эш графигы, шулай ук Министрлыкның электрон почта адресы турында мәгълүмат бүлек белгече тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында (http://frgu.tatar.ru) һәм Республикасы порталында урнаштырыла.

Бердәм порталда, Республика порталында Республика реестрында булган белешмәләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турындагы мәгълүмат мөрәҗәгать итүчегә бушлай бирелә.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитларын һәм аларны рәсми басылып чыгу чыганакларын да күрсәтеп) «Интернет» челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

техник хата – Министрлык җибәргән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу хатасы, басма хата, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата);

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәр округының яки муниципаль районының шәһәр (авыл) җирлегендә оештырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать турында сүз бара («Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясындагы 1 пункты (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон).

Гаризаларның киңәш ителә торган рәвешләре әлеге Регламентның 1-4 нче кушымталарында китерелгән.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

### 2.1. Дәүләт хезмәте атамасы

Кара металл, төсле металл ватыклары әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү.

2.2. Башкарма хакимият органының атамасы

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама

Лицензиатка җибәрелгән (бирелгән) лицензия бирү турында белдерү (Регламентка 10 нчы кушымта);

лицензиатка җибәрелгән (бирелгән) лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында белдерү (Регламентка 11 нче кушымта);

лицензиатка җибәрелгән (бирелгән) лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында белдерү (Регламентка 14 нче кушымта);

лицензия алырга теләүче затка җибәрелгән (бирелгән) лицензия бирүдән баш тарту турында белдерү (Регламентка 12 нче кушымта);

лицензиатка җибәрелгән (бирелгән) лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында белдерү (Регламентка 13 нче кушымта).

Кара металл, төсле металл калдыкларын әзерләүгә, саклауга, эшкәртүгә һәм сатуга лицензияләр реестрында (алга таба – лицензияләр реестры) язу.

Лицензияләр реестрыннан өземтә, яисә кабул ителгән карар турында Министрлык акты күчермәсе, яисә соратып алына торган белешмәләрнең булмавы турында белешмә, анысы лицензияләр реестрында лицензияләр турында мәгълүмат булмаган яки конкрет лицензиатны билгеләү мөмкин булмаган очракта бирелә.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) вакыты

Лицензия бирү тиешенчә рәсмиләштерелгән, лицензия бирү турында гариза һәм аңа теркәп тапшырыла торган документлар тулы күләмендә теркәлгәннән соң 30 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү (юридик зат яки шәхси эшкуар тарафыннан лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру адреслары, эшчәнлекнең лицензияләнә торган төреннән гыйбарәт, башкарыла торган эшләр исемлеге үзгәртелгән очракларда) лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән гариза һәм аңа теркәп тапшырыла торган документлар тулы күләмендә теркәлгәннән соң 30 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү (юридик затны үзгәртеп кору, аның атамасын, урнашкан урынын үзгәртү формасында юридик зат үзгәртеп корылган очракларда, шулай ук шәхси эшкуарның яшәгән урыны, исеме, фамилиясе һәм (булган очракта) атасының исеме, аның шәхесен таныклый торган документ реквизитлары үзгәртелгәндә, эшчәнлекнең лицензияләнә торган төрен гамәлгә ашыру урыннарының аерым адреслары буенча эшчәнлек туктатылган очракларда) лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында тиешенчә рәсмиләштерелгән гариза

һәм аңа теркәп тапшырыла торган документлар тулы күләмендә теркәгәннән соң тугыз эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Лицензиянең гамәлдә булуын туктату лицензиатның лицензиянең гамәлдә булуын туктату турындагы гаризасы теркәлгәннән соң биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Лицензияләр реестрыннан белешмәләр бирү лицензияләр реестрыннан белешмәләр бирү турындагы гаризаны теркәгәннән соң өч эш көне эчендә башкарыла.

Лицензияләр реестрына лицензия бирү (үзгәртеп рәсмиләштерү), лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында язу кертелгән көннән соң өч эш көнендә Министрлык лицензияне бирү (үзгәртеп рәсмиләштерү), лицензиянең гамәлдә булуын туктату турындагы белдерүне лицензиатка, аның ихтыярына карап, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында яисә, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы итеп кәгазьдә җибәрә.

Лицензия бирүдән (үзгәртеп рәсмиләштерүдән) баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, Министрлык әлеге карар кабул ителгәннән соң өч эш көне эчендә лицензия алырга теләүче затка (лицензиатка), аның ихтыярына карап, баш тарту өчен нигез булган норматив хокукый актларның яки башка документларның конкрет нигезләмәләренә сылтама ясап, баш тарту нигезләрен дәлилле нигезләп, лицензия бирүдән (үзгәртеп рәсмиләштерүдән) баш тарту турындагы белдерүне яки, баш тарту нигезе булып тикшерү барышында лицензия алырга теләүче затның (лицензиатның) лицензия таләпләренә туры килмәвенең ачыклануы хезмәт иткән булса, лицензия алырга теләүче затны (лицензиатны) тикшерү актының реквизитларын тапшыра, яки, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы итеп җибәрә яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында юллый.

Лицензияләр реестры Министрлыкның рәсми сайтында һәркем файдалана алырлык итеп урнаштырылган.

Мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткән очракта, гаризаны һәм теркәлә торган документларны Министрлык белән күпфункцияле үзәк арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда Министрлыкка тапшыру тәэмин ителә. Дәүләт хезмәте күрсәтелгән вакытка гаризаның күпфункцияле үзәктә булган вакыты һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе күпфункцияле үзәктән Министрлыкка тапшыру вакыты керми.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документ мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документны гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып (почта буенча, Республика порталында, Бердәм порталда шәхси кабинет аша) җибәрү дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе

1. Лицензия алу өчен:

а) лицензия бирү турында гариза (Регламентка 1 нче кушымта);

б) лицензия алырга теләүче затта лицензияләнә торган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле һәм милекчелек хокукында яки законлы башка нигездә анықы булган, аларга карата хокуклар Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында теркәлгән (мондый хокуклар әлеге реестрда теркәлгән очракта, әлеге җир кишәр-лекләре, биналар, төзелмәләр, корылмалар һәм бүлмәләр турында белешмәләр тапшырыла) җир кишәрлекләренең, биналарның, төзелмәләрнең, корылмаларның һәм бүлмәләрнең (биналарның, төзелмәләрнең, корылмаларның һәм бүлмәләрнең аерымланган бердәм өлеше) булуын раслый торган документларның күчермәләре;

в) лицензия алырга теләүче затта милекчелек хокукында яки законлы башка нигездә анықы булган техник чараларның, җайланмаларның һәм лицензияләнә торган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кулланыла торган техник документларның булуын раслый торган документларның күчермәләре;

г) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2001 елның 11 маендагы 369 номерлы карары белән расланган Кара металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләре (алга таба – Кара металл ватыклары белән эш итү кагыйдәләре) һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2001 елның 11 маендагы 370 номерлы карары белән расланган Төсле металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү кагыйдәләре (алга таба – Төсле металл ватыклары белән эш итү кагыйдәләре) таләпләре нигезендә лицензия алырга теләүче зат белән хезмәт килешүләрен төзегән хезмәткәрләрнең квалификациясен раслый торган документларның күчермәләре;

д) Кара металл ватыклары белән эш итү кагыйдәләре һәм Төсле металл ватыклары белән эш итү кагыйдәләре таләпләренә туры китереп лицензия алырга теләүче зат җитәкчесе раслаган ватыкларга һәм калдыкларга радиация контролен уздыру һәм ватыкларга һәм калдыкларга шартлау хәтәрлеге буенча контроль уздыру өчен җаваплы затлар билгеләү турындагы документларның күчермәләре;

е) теркәлә торган документлар исемлеге.

2. Лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү өчен (юридик зат яисә шәхси эшкуар тарафыннан лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урыннарының адреслары, лицензияләнә торган эшчәнлек төрен тәшкил итүче башкарыла торган эшләр исемлеге үзгәртелгән очракларда):

а) лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гариза (Регламентка 2 нче кушымта);

б) 1 пунктның «б», «в», «г», «д» пунктчаларында күрсәтелгән белешмәләре булган документларның күчермәләре;

в) теркәлә торган документлар исемлеге.

3. Лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү өчен (юридик затны үзгәртеп кору, аның атамасын үзгәртү, урнашкан урынын үзгәртү рәвешендә юридик зат үзгәртеп корылган очракларда, шулай ук шәхси эшкуарның яшәгән урыны, исеме, фамилиясе һәм (булган очракта) атасының исеме, аның шәхесен таныклый торган документ реквизитлары үзгәртелгәндә, лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урыннарының аерым адреслары буенча эшчәнлек туктатылган очракларда):

а) лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гариза (Регламентка 2 нче кушымта).

4. Лицензиянең гамәлдә булуын туктату өчен:
лицензиатның лицензиянең гамәлдә булуын туктату турындагы гаризасы (Регламентка 3 нче кушымта).

5. Лицензияләр реестрыннан белешмәләр бирү өчен:
лицензияләр реестрыннан белешмәләр бирү турында гариза (Регламентка 4 нче кушымта).

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Мөрәҗәгать итүче лицензия бирү турында гаризаны һәм аңа теркәп тапшырыла торган документларны электрон документлар (электрон документлар пакеты) рәвешендә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җибәрә.

Мөрәҗәгать итүчене идентификацияләү һәм аутентификацияләү «Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итүче инфраструктурада идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» (алга таба – идентификация һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы) федераль дәүләт мәгълүмат системасын кулланып гамәлгә ашырыла.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе буенча тапшырыла (җибәрелә) ала:
1) Министрлыкка шәхсән яисә почта аша кәгазьдә.
2) күпфункцияле үзәк аша кәгазьдә.
Гаризаны тапшырган вакытта мөрәҗәгать итүчегә күпфункцияле үзәктән гаризаның кабул ителүен раслый торган теркәү номеры белән язу бирелә;
3) Бердәм портал аша;
4) Республика порталы аша.

Гаризаны Бердәм портал, Республика порталы аша җибәргәндә мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне Бердәм порталда, Республика порталында шәхси кабинетында гаризаның кабул ителүен һәм гаризаны тапшыру датасы буенча раслама ала.

Гаризаны Бердәм портал, Республика порталы аша тапшырганда мөрәҗәгать итүче «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) таләпләренә туры китереп, мондый документларны эшләү һәм имзалау өчен вәкаләтле затларның электрон имзасы белән имзаланган документларны электрон формада тапшыра.

Мөрәҗәгать итүчеләр лицензия алу (үзгәртеп рәсмиләштерүгә, гамәлдә булуын туктату) турындагы гаризаны һәм кирәкле документларны Бердәм портал, Республика порталы аша җибәргәндә гаризаны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалый.

Мөрәҗәгать итүчеләр лицензияләр реестрыннан мәгълүматлар бирү турындагы гаризаны Бердәм портал, Республика порталы аша җибәргән очракта, гаризаны гади электрон имза белән имзалыйлар.

2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм Мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, Мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма

Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында түбәндәгеләр тапшырыла:

б) лицензия алырга теләүче затта (лицензиатта) милек хокукында яисә законлы башка нигездә аныкы булган җир кишәрлеге, биналар, корылмалар булуын раслый торган мәгълүматлар (Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә);

в) Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсендә);

г) Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсендә).

Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.

Мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торганын да, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статья-сының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә электрон рәвешләре элегрәк таныкланган документларны һәм мәгълүмат-ларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.

## 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза билгеләнгән таләпләрне бозып рәсмиләштерелгәндә;
2) әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар тулысы белән тапшырылмаганда;
3) дәүләт хезмәте күрсәтү хокукына ия булмаган зат мөрәҗәгать иткәндә;
4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт пошлинасы түләнмәгән очракта;
5) дәүләт һәм муниципаль түләүләр турындагы дәүләт мәгълүмат системасында лицензияләр реестрыннан кәгазьдә өземтә биргән өчен түләнгәнлек турында белешмәләр булмавы;
6) электрон формадагы гариза һәм башка документлар 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен бозып, электрон имза белән имзаланган очракта.

## 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

лицензия бирү өлешендә:

лицензия бирү турында тапшырылган гаризада һәм (яки) аңа теркәлә торган документларда дөрес булмаган яки ялган мәгълүмат булуы;

тикшерү барышында лицензия алырга теләүченең лицензия таләпләренә туры килмәве ачыкланганда;

лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү өлешендә:

лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында тапшырылган гаризада һәм (яки) аңа теркәлә торган документларда дөрес булмаган яки ялган мәгълүмат булуы;

тикшерү барышында лицензиатның лицензия таләпләренә туры килмәгәнлеге ачыклану.

Лицензиянең гамәлдә булуын туктату, лицензияләр реестрыннан белешмәләр бирү өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр юк.

## 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре

Дәүләт хезмәте түләүле нигездә күрсәтелә.

Дәүләт пошлинасы:

лицензия бирү – 7500 сум;

лицензияләнгән эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урыннарының адреслары, лицензияләнә торган эшчәнлек төре составында башкарыла торган эшләр турында белешмәләргә өстәмәләр кертү белән бәйле рәвештә лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү – 3500 сум;

башка очракларда лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү – 750 сум.

Лицензияне үзгәртеп рәсмиләштергән очракта, дәүләт пошлинасын түләүне таләп итә торган бер нигез буенча иң зур дәүләт пошлинасы түләнә.

Дәүләт пошлинасын түләү реквизитлары:
БАНК РОССИЯ БАНКЫНЫҢ ТР МИЛЛИ БАНКЫ БҮЛЕКЧӘСЕ//Татарстан Республикасы буенча ФКИ Казан шәһәре
БИК 019205400
казначылык счеты номеры 03100643000000011100
исәп счеты 40102810445370000079
алучы:
Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, шәхси счет: 04112001020)
ИНН 1655141501
КПП 165501001
ОГРН 1071690045129
ОКПО 82318720
ОКВЭД 84.11.21
ОКТМО 92701000
КБК түләү идентификаторы 70210807082011000110

Түләнгән дәүләт пошлинасы, дәүләт пошлинасын түләгән затларның юридик яктан әһәмиятле гамәл кылудан баш тарткан очракта, әлеге юридик әһәмияткә ия гамәлне кылган (кыла торган) вәкаләтле органга (вазыйфаи затка) мөрәҗәгать иткәнчегә кадәр өлешчә яисә тулысынча кире кайтарылырга тиеш.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча тапшырылган документка Министрлык һәм (яки) вазыйфаи зат, күпфункцияле үзәк һәм (яки) күпфункцияле үзәк хезмәткәре гаебе белән җибәрелгән хаталарны төзәтүгә юнәлдерелгән үзгәрешләр кертелгән очракта, мөрәҗәгать итүчедән түләү алынмый.

Лицензияләр реестрыннан кәгазь нөсхәдә өземтә түләүле рәвештә бирелә.
Лицензияләр реестрыннан кәгазь өземтә биргән өчен түләү (алга таба – түләү) күләме 3000 сум тәшкил итә.

Түләү реквизитлары:
БАНК РОССИЯ БАНКЫНЫҢ ТР МИЛЛИ БАНКЫ БҮЛЕКЧӘСЕ//Татарстан Республикасы буенча ФКИ Казан шәһәре
БИК 019205400
казначылык счеты номеры 03100643000000011100
исәп счеты 40102810445370000079
алучы:
Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, шәхси счет: 04112001020)
ИНН 1655141501
КПП 165501001
ОГРН 1071690045129
ОКПО 82318720
ОКВЭД 84.11.21
ОКТМО 92701000

КБК түләү идентификаторы 70211301410010000130.

Түләү кире кайтарылырга тиеш:

тулы күләмдә, әгәр Министрлыкка кәгазьдәге өземтә рәвешендә конкрет лицензия турында лицензияләр реестрыннан мәгълүматлар бирү турында гариза тапшырылмаган булса;

билгеләнгән түләү күләменнән артып киткән күләмдә түләү кертелгән очракта, билгеләнгән түләүне арттырган өлешендәге күләмдә;

түләү тулы күләмдә кертелмәгән очракта, кертелгән түләү күләмендә.

Түләүне кире кайтару турында гариза түләү кертелгәннән соң өч ел эчендә тапшырылырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүче өземтә алудан баш тарткан очракта, аны бирү өчен кертелгән түләү кире кайтарылмый.

Шулай ук түләү лицензия реестрында соратып алына торган мәгълүматлар булмаган очракта да кире кайтарылмый.

Бүлек белгеченең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендәге лицензияләр реестрыннан өземтә түләү алмыйча бирелә.

### 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

### 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

### 2.12. Дәүләт хезмәтен, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артык булырга тиеш түгел.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

### 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатен теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада да

Гариза алынган көннән соң бер көн эчендә теркәлә.

Мөрәҗәгать итүче яки аның вәкиле тарафыннан күпфункцияле үзәк аша бирелгән гариза Министрлык тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гариза күпфункцияле үзәктән алынган көнне теркәлә.

Бердәм порталга, Республика порталына электрон рәвештә кергән гариза кергән көнендә теркәлә.

Ял (бәйрәм) көнендә, эшләми торган вакытта электрон формада кергән гариза икенче эш көненә теркәлә.

## 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр

Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, һаваны кондиционерлау системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла.

Катнашу урыны Татарстан Республикасы Телекоммуникацияләрнең дәүләт интеграция системасына тоташтырылган электрон мәгълүмат киоскы (инфомат) белән җиһазландырыла.

Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм озата йөри торган этләрдән файдаланучыларга да, биналардан, бүлмәләрдән файдалану һәм хезмәт күрсәтә алу шартларын тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла:

бинага һәм бүлмәләргә каршылыксыз үтеп керү, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән каршылыксыз файдалана алу шартлары;

Министрлык территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, Министрлык бинасына һәм бүлмәләренә керү һәм чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;

күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга бинада һәм бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;

инвалидларның бинадан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;

инвалидларның бинадан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;

инвалидлар өчен кирәкле булган, ишетелә һәм күренә торган мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм Брайльның нокталы шрифтлары белән ясалган текстлы һәм тамгалы башка график мәгълүматларны дубльләштерү, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм этнең махсус өйрәтелгән булуын раслый торган документы булган очракта, бинага һәм бүлмәләргә озата йөри торган этне кертү;

хезмәт күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр күрсәтә алуга комачаулый торган каршылыкларны бетерүдә ярдәм күрсәтү.

2016 елның 1 июленнән соң капиталь ремонт, реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәтеннән һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгатьне) тапшыру юлы белән, җирле үзидарәнең үтәү-боеру органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәте күрсәтү (шул исәптән тулы күләмдә) мөмкинлеге яки күрсәтү мөмкинлегенең булмавы

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;

дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан Регламент бозылу очракларына карата нигезләнгән шикаятьләрнең булмавы.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Министрлык бүлмәләренең җәмәгатьчелек транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;

кирәкле санда белгечләр, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булуы;

мәгълүмат стендларында, Интернет челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы;

электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;

инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләр күрсәтүгә комачаулаган каршылыкларны бетерүдә ярдәм итү;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуы, инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр күрсәтүгә комачаулый торган башка каршылыкларны бетерүдә ярдәм күрсәтү;

гаризаны һәм документларны электрон документлар рәвешендә Бердәм портал, Республика порталы аша тапшырган очракта, мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм порталда, Республика порталында шәхси кабинет аша дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон рәвештә алу мөмкинлеге.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда бүлек белгече белән мөрәҗәгать итүченең дүрт тапкыр үзара хезмәттәшлеге күздә тотыла (гариза тапшыру, документар тикшерү актын имзалау, күчмә тикшерү актын имзалау, лицензия алу). Хезмәттәшлек итүнең дәвамлылыгы Регламент белән билгеләнә.

Дәүләт хезмәте күпфункцияле үзәктә күрсәтелгән очракта, документларны кабул итү һәм бирү күпфункцияле үзәк белгече тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Министрлык белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек итү тәртибе – Министрлык һәм күпфункцияле үзәк арасында төзелә торган хезмәттәшлек турындагы килешү белән, ә күпфункцияле үзәкнең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү тәртибе күпфункцияле үзәкнең эш регламентында җайга салына.

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкта, Бердәм порталда, Республика порталында шәхси кабинеттан, күпфункцияле үзәктән алынырга мөмкин.

Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

### 2.16. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган башка таләпләр

Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документлар тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

д) дәүләт хезмәте Республика порталы аша күрсәтелгәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазьдә алырга;
е) Республика порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Бердәм порталда, Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе Бердәм портал, Республика порталы аша көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә бирелә.

Мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итүгә язу (алга таба – кабул итүгә язу) Республика порталы, күпфункцияле үзәкнең элемтә үзәге телефоны аша гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә күпфункцияле үзәктә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә буш булган теләсә нинди кабул итү датасына һәм вакытына язылу мөмкинлеге бирелә.

Билгеле бер датага язылу вакыты әлеге дата башланырга бер тәүлек калгач бетә.

Республика порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен мөрәҗәгать итүчегә системада сорала торган белешмәләрне күрсәтергә кирәк, шул исәптән:
фамилиясен, исемен һәм атасының исемен (булган очракта);
телефон номерын;
электрон почта адресы;
кабул итүнең теләнгән датасын һәм вакытын.

Алдан язылганда мөрәҗәгать итүче күрсәткән белешмәләр мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул иткәндә тапшырылган документларга туры килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә талон-раслама чыгартып алу мөмкинлеге бирелә. Әгәр мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын күрсәтсә, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Алдан язылганда билгеләнгән кабул итү вакыты башланып, 15 минут узганнан соң да килмәгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә алдан язылуның гамәлдән чыгарылуы турында зарури тәртиптә мәгълүмат җиткерелә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тарта ала.

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификациялауне һәм аутентификацияләүне узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан броньлап кую өчен кирәкле вакыт аралыгы озынлыгын исәпләү өчен кирәкле белешмәләр тапшырудан тыш,

мөрәҗәгать итүчедән бүтән гамәлләр кылуны таләп итү тыела.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә гамәлгә ашыру үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләр эзлеклелегенә тасвирлама.

Кара металл, төсле металл ватыклары әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) лицензия алырга теләүче затка, лицензиатка консультация бирү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү буенча да;

2) лицензия бирү:

а) күпфункцияле үзәктән, Бердәм порталдан, Республика порталыннан, Министрлыкка язмача мөрәҗәгать иткәндә алынган гаризаны кабул итү һәм теркәү;

б) планнан тыш документар тикшерү үткәрү, шул исәптән ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

в) планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

д) лицензия алырга теләүче затка дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү;

3) лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү (юридик зат яисә шәхси эшкуар тарафыннан лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урыннарының адреслары, лицензияләнә торган эшчәнлек төрен тәшкил итүче башкарыла торган эшләр исемлеге үзгәртелгән очракларда):

а) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

б) планнан тыш документар тикшерү үткәрү, шул исәптән ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

в) планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

д) лицензиатка дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү;

4) лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү (юридик затны үзгәртеп кору, аның атамасын үзгәртү, урнашкан урынын үзгәртү рәвешендә юридик зат үзгәртеп корылган очракларда, шулай ук шәхси эшкуарның яшәгән урыны, исеме, фамилиясе һәм (булган очракта) атасының исеме, аның шәхесен таныклый торган документ реквизитлары үзгәртелгәндә, лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урыннарының аерым адреслары буенча эшчәнлек туктатылган очракларда):

а) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

б) планнан тыш документар тикшерү үткәрү, шул исәптән ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

в) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

г) лицензиатка дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү;

5) лицензиянең гамәлдә булуын туктату:
а) гаризаны кабул итү һәм теркәү;
б) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;
в) лицензиатка дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү;
6) лицензияләр реестрыннан белешмәләр бирү:
а) гаризаны кабул итү һәм теркәү;
б) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;
в) лицензиатка дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү;
7) техник хаталарны төзәтү.

3.2. Лицензия алырга теләүче затка, лицензиатка консультация бирү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү буенча да.

Лицензиягә дәгъва белдерүче зат, лицензиат дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында консультация сорап, күпфункцияле үзәккә шәхсән яки телефон аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәре лицензия алырга теләүчене, лицензиатны консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырыла торган документларның составы, формасы буенча һәм башка мәсьәләләрдә дә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүматны күпфункцияле үзәк (http://mfc16.tatarstan.ru/) сайтыннан ирекле файдалану юлы белән алырга мөмкин.

Лицензия алырга теләүче зат, лицензиат телефон һәм (яки) электрон почта аша дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында консультацияләр алу өчен бүлеккә мөрәҗәгать итә.

Бүлек белгече лицензия алырга теләүче затка, лицензиатка, шул исәптән тапшырыла торган документларның составы, формасы буенча да консультацияләр бирә, мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен башка мәсьәләләр буенча да ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар лицензия алырга теләүче зат, лицензиат мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм лицензияләүнең башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.

3.3. Лицензия бирү.

3.3.1. Гариза Министрлыкка шәхсән, ышанычлы зат аша, почта буенча, Бердәм портал, Республика порталы, күпфункцияле үзәк аша тапшырылырга мөмкин.

Лицензия алырга теләүче зат лицензия бирү турында гаризаны һәм Регламентның 2.5 пунктының 1 пунктчасы нигезендә аңа теркәп тапшырыла торган документларны, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, электрон документлар (электрон документлар пакеты) рәвешендә җибәрә.

Гаризаны һәм теркәп тапшырыла торган документларны мөрәҗәгать итүче Министрлыкның оештыру идарәсенең эшчәнлек башкару бүлегенә (алга таба – эшчәнлек башкару бүлегенә) турыдан-туры кәгазьдә тапшырырга яисә, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы итеп җибәрергә хокуклы.

Гаризаны Бердәм портал, Республика порталы аша электрон формада тапшырган очракта, мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

Бердәм порталда, Республика порталында авторизацияләнә;

Бердәм порталда, Республика порталында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле тамга билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза формасындагы тиешле төймәгә баса);

электрон гариза 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә гади электрон имза белән яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Гаризаны күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны аша тапшырган очракта, күпфункцияле үзәкнең гаризаларны кабул итә торган белгече:

гариза белән документларны кабул итә;

гаризаны терки;

гариза тутыруның тулылыгын һәм дөреслеген тикшерә;

лицензия алырга теләүчегә, лицензиатка гариза җибәрү датасы турында хәбәр итә;

документлар пакетын формалаштыра һәм аны күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән тәртиптә аны Министрлыкка җибәрә.

Регламентның әлеге пунктында билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә гамәлгә ашырыла: гариза Министрлыкка, Бердәм портал, Республика порталы аша тапшырылган очракта, мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне; гаризаны күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны аша тапшырган очракта, күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән срокларда.

Процедураларның нәтиҗәсе: Министрлыкка җибәрелгән гариза.

3.3.2. Эшчәнлек башкару бүлеге белгече:

лицензия бирү турындагы гаризаны һәм аңа теркәп тапшырыла торган документларны исемлеге буенча кабул итә;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының бердәм электрон документ әйләнеше ведомствоара системасында (алга таба – Электрон Хөкүмәт) лицензия бирү турындагы гаризаны терки;

лицензия алырга теләүче затка лицензия бирү турындагы гаризаны һәм аңа

теркәлә торган документларны кабул итү датасын тамгалап, исемлек күчермәсен тапшыра яки, лицензия алырга теләүче зат ихтыяры буенча, кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы итеп, лицензияләүче органның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә мондый күчермәнең лицензия алырга теләүче зат тарафыннан алынуын һәм әлеге документның илтеп җиткерелүен раслый торган ысул белән җибәрә;

лицензия бирү турындагы гаризаны һәм аңа теркәп тапшырыла торган документларны исемлеге буенча бүлеккә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар лицензия бирү турында гариза һәм аңа теркәп тапшырыла торган документлар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: лицензия бирү турында теркәлгән, карау өчен бүлеккә җибәрелгән гариза һәм аңа теркәп тапшырыла торган документлар.

3.3.3. Бүлек белгече:

лицензия эшен рәсмиләштерә;

лицензия алырга теләүче зат турындагы мәгълүматны Министрлыкның рәсми сайтында урнаштыра;

Регламентка 1 нче кушымтада күрсәтелгән, билгеләнгән формалы лицензия бирү турындагы гаризаны рәсмиләштерүнең ярашлылыгын тикшерә;

Регламентның 2.5 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән, тапшырылган документлар пакеты составының тулылыгын тикшерә;

Дәүләт һәм муниципаль түләүләр турындагы дәүләт мәгълүмат системасында дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасының түләнгән булу-булмавын тикшерә;

тапшырылган документларны тикшерә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен Регламентның 2.7 пунктында каралган нигезләр булуын (булмавын) билгели.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен Регламентның 2.7 пунктындагы 3, 4, 6 пунктчаларында каралган нигезләр ачыкланган очракта, бүлек белгече сәбәп-ләрен күрсәтеп, документларны кабул итүдән баш тарту турында белдерү әзерли (Регламентка 9 нчы кушымта), лицензия алырга теләүче затка аны тапшыра яисә, лицензия алырга теләүче затның ихтыярына карап, лицензияләүче органның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә, мондый белдерүнең җиткерелүен һәм лицензия алырга теләүче зат тарафыннан алынуын раслый торган ысул белән, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы итеп җибәрә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен Регламентның 2.7 пунктындагы 1, 2 пунктчаларында каралган нигезләр ачыкланган очракта, бүлек белгече утыз көн эчендә ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү кирәклеге һәм (яки) җитешмәгән документларны тапшыру турында лицензия алырга теләүче затка белдерү (Регла-ментка 5 нче кушымта) бирә яки мондый белдерүне, лицензия алырга теләүче зат ихтыярына карап, лицензияләүче органның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә, мондый белдерүнең җиткерелүен һәм лицензия алырга теләүче зат тарафыннан алынуын раслый торган ысул белән, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы итеп җибәрә. Лицензия алырга теләүче зат тарафыннан, белдерү алынган вакыттан

башлап, лицензия бирү турында тиешенчә рәсмиләштерелгән гариза һәм (яки) аңа теркәп тапшырыла торган документлар утыз көнлек срокта тулы күләмдә тапшырылмаган очракта, лицензия бирү турында элек тапшырылган гариза һәм аңа теркәп тапшырыла торган документлар лицензия алырга теләүче затка кире кайтарылырга тиеш.

Регламентның 2.7 пунктындагы 1, 2, 3, 4, 6 пунктларындагы документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булмаса, бүлек белгече планнан тыш документар тикшерү үткәрү турында боерык проекты әзерли.

Бүлек җитәкчесе, юридик бүлек җитәкчесе планнан тыш документар тикшерү үткәрү турында боерык проектын килештерә, ул лицензияләү мәсьәләләрен алып баручы министр урынбасарына (алга таба – министр урынбасары) җибәрелә.

Министр урынбасары планнан тыш документар тикшерү үткәрү турындагы боерыкны имзалый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаган көннән соңгы бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: планнан тыш документар тикшерү үткәрү турында боерык яисә ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү һәм (яки) булмаган документларны тапшыру зарурлыгы турында белдерү, лицензия бирү турында тапшырылган гаризаны һәм аңа теркәп бирелә торган документларны кире кайтару турында белдерү (Регламентка 7 нче кушымта), документларны кабул итүдән баш тарту турында белдерү.

Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы, ягъни лицензия бирү яисә аны бирүдән баш тарту турында карар кабул итү вакыты лицензия бирү турында тиешенчә рәсмиләштерелгән гариза һәм аңа теркәп тапшырыла торган документлар тулы күләмендә Министрлыкка кергән көннән исәпләнә башлый.

3.3.4. Бүлек белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон рәвештә рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яисә Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә бирү турында – Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә.

лицензия алырга теләүче затта (лицензиатта) милек хокукында яисә законлы башка нигездә аныкы булган җир кишәрлеге, биналар, корылмалар булуын раслый торган белешмәләрне бирү турында, – Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсенә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Регламентның 3.3.2 пунктында каралган процедураны тәмамлау көненнән соңгы бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.3.5. Белешмәләр белән тәэмин итүче белгечләр ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә сорала торган документларны (мәгълүматны) бирә яисә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документның һәм (яисә) мәгълүматның булмавы турында хәбәр (алга таба – документның һәм (яисә) мәгълүматның булмавы турында хәбәр) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар, законнарда билгеләнгән срокларда җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә мәгълүмат белән тәэмин итүче зат тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлеккә җибәрелгән документлар (мәгълүматлар) яки баш тарту турында белдерү.

3.3.6. Бүлек белгече Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 мартындагы 96 номерлы боерыгы белән расланган Кара металл, төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә лицензия контролен гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан башкаруның административ регламенты (алга таба – Административ регламент) таләпләре нигезендә планнан тыш тикшерү үткәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Регламентның 3.3.3 пунктында каралган процедура тәмамланган көннән соңгы егерме эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тикшерү акты.

3.3.7. Лицензия бирү өлешендә әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган хезмәт күрсәтүдән баш тарту нигезләре ачыкланган очракта, бүлек белгече лицензия бирүдән баш тарту турында боерык проекты әзерли һәм аны, килештерү өчен, бүлек җитәкчесенә, юридик бүлек җитәкчесенә җибәрә.

Бүлек җитәкчесе, юридик бүлек җитәкчесе лицензия бирүдән баш тарту турында боерык проектын килештерә, ул министр урынбасарына имзалау өчен җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаган көннән соңгы бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: лицензия бирүдән баш тарту турындагы боерыкның расланган, министр урынбасарына имзалау өчен җибәрелгән проекты.

3.3.8. Министр урынбасары лицензия бирүдән баш тарту турындагы боерыкны имзалый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаган көннән соңгы бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: лицензия бирүдән баш тарту турында имзаланган боерык.

3.3.9. Бүлек белгече лицензия алырга теләүче затка, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, лицензия бирүдән баш тарту турындагы белдерүне тапшыра яки, лицензия алырга теләүче зат ихтыярына карап, аны кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура лицензия бирүдән баш тарту турындагы боерык имзаланганнан соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензия бирүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, баш тарту турында белдерү.

3.3.10. Бүлек җитәкчесе, юридик бүлек җитәкчесе, планнан тыш урынга чыгып тикшерү үткәрү кирәк булган очракта, планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы боерык проектын килештерә, ул министр урынбасарына җибәрелә. Планнан тыш тикшерү Контрольлек буенча административ регламентында күрсәтелгән нигез

буенча һәм тәртиптә башкарыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Регламентның 3.3.6 пунктында каралган процедураны тәмамлау көненнән соңгы бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: министр урынбасарына җибәрелгән планнан тыш тикшерү үткәрү турында боерык проекты.

3.3.11. Министр урынбасары планнан тыш урынга чыгып тикшерү үткәрү турындагы боерыкны имзалый; бүлек белгече лицензия алырга теләүче затка Административ регламент нигезендә контрольлек буенча планнан тыш тикшерү үткәрү датасы турында хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаган көннән соңгы ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: планнан тыш урынга чыгып тикшерү үткәрү турында имзаланган боерык; лицензия алырга теләүче затка планнан тыш тикшерү үткәрү датасы турында теләсә нинди үтемле ысул белән хәбәр итү.

3.3.12. Бүлек белгече (белгечләре) лицензия алырга теләүче затның лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру өчен үзе тарафыннан белдерелгән урында лицензиат тарафыннан лицензия таләпләрен үтәү мөмкинлегенә карата планнан тыш күчмә тикшерү үткәрә (үткәрәләр).

Планнан тыш тикшерү нәтиҗәләре буенча ике нөсхәдә тикшерү акты рәсмиләштерелә.

Тикшерү актының беренче нөсхәсе лицензия эшенә тегелә. Тикшерү актының икенче нөсхәсе лицензия алырга теләүче затка тапшырыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаган көннән соңгы өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тикшерү акты.

3.3.13. Лицензия алырга теләүче затның лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урынында лицензия таләпләрен үтәү мөмкинлеге булмаган очракта, ул тикшерү актында чагылдырыла, Регламентның 3.3.7-3.3.9 пунктларында каралган процедуралар гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: лицензия бирүдән баш тарту турында боерык, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, лицензия бирүдән баш тарту турында белдерү (Регламентка 12 нче кушымта).

3.3.14. Лицензия алырга теләүче затның лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урынында лицензия таләпләрен үтәү мөмкинлегенең булуы билгеләнгән очракта, ул тикшерү актында чагылдырыла, бүлек җитәкчесе, юридик бүлек җитәкчесе лицензия бирү турында боерык проектын килештерә, ул министр урынбасарына имзалау өчен җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Регламентның 3.3.12 пунктында каралган процедураны тәмамлау көненнән соңгы бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: лицензия бирү турында министр урынбасарына имзалау өчен җибәрелгән, килештерелгән боерык проекты.

3.3.15. Министр урынбасары лицензия бирү турындагы боерыкны имзалый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедураны тәмамлаган

көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензия бирү турында имзаланган боерык.

3.3.16. Бүлек белгече, лицензия бирү турында имзаланган боерык нигезендә, лицензия бирү турындагы язуны, шул исәптән лицензия бирү турындагы боерык реквизитларын да, лицензияләр реестрына кертә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура лицензия бирү турындагы боерык имзаланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензияләр реестрына кертелгән лицензия бирү турындагы язу.

3.3.17. Бүлек белгече лицензиатка, аның ихтыярына карап, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында яки, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы итеп кәгазьдә лицензия бирүдән баш тарту турында белдерү (Регламентка 10 нчы кушымта) җибәрә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү өчен күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткән очракта, күпфункцияле үзәк хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазьдә бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар чират тәртибендә, мөрәҗәгать итүче килгән көнне күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүче Бердәм портал, Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган электрон документ, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланып, шәхси кабинетка автомат җибәрелә.

Лицензия бирү турындагы гаризада лицензияне алырга теләгән зат электрон документ формасында лицензияләр реестрыннан өземтә алу зарурлыгына күрсәткән булса, лицензияләүче орган, лицензия бирү турындагы белдерү җибәрү белән бер үк вакытта, лицензияләр реестрыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган, электрон документ формасындагы өземтәне дә лицензиатка җибәрә.

Лицензия алу турындагы гаризада лицензияне алырга теләгән зат лицензияләр реестрыннан кәгазьдә өземтә алу зарурлыгына күрсәткән булса, лицензияләүче орган, лицензия бирү турындагы белдерү җибәрү белән бер үк вакытта, кулга тапшыру турында белдереп, лицензиатка заказлы почта юлламасы итеп лицензияләр реестрыннан өземтә җиткерә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Регламентның 3.3.15 пунктында каралган процедура тәмамланган көннән соңгы өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: лицензиатка лицензия бирү турында белдерү, кирәк булган очракта лицензияләр реестрыннан өземтә.

### 3.4. Лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү (юридик зат яисә шәхси эшкуар тарафыннан лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урыннарының адреслары, лицензияләнә торган эшчәнлек төрен тәшкил итүче башкарыла торган эшләр исемлеге үзгәртелгән очракларда)

3.4.1. Гариза Министрлыкка шәхсән, ышанычлы зат аша, почта буенча, Бердәм портал, Республика порталы, күпфункцияле үзәк аша тапшырылырга мөмкин.

Гариза һәм аңа теркәп тапшырыла торган документларны мөрәҗәгать итүче эшчәнлек башкару бүлегенә турыдан-туры кәгазьдә тапшырырга яисә, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы итеп җибәрергә хокуклы.

Лицензиат лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гаризаны һәм Регламентның 2.5 пунктының 2 пунктчасы нигезендә аңа теркәп тапшырыла торган документларны, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, электрон документлар (электрон документлар пакеты) рәвешендә җибәрә.

Гаризаны күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны аша тапшырган очракта, күпфункцияле үзәкнең гаризаларны кабул итә торган белгече:

гариза белән документларны кабул итә;

гаризаны терки;

гариза тутыруның тулылыгын һәм дөреслеген тикшерә;

лицензия алырга теләүчегә, лицензиатка гариза җибәрү датасы турында хәбәр итә;

документлар пакетын формалаштыра һәм аны күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән тәртиптә аны Министрлыкка җибәрә.

Регламентның әлеге пунктында билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә гамәлгә ашырыла: гариза Министрлыкка, Бердәм портал, Республика порталы аша тапшырылган очракта, мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне; гаризаны күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны аша тапшырган очракта, күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән срокларда.

Процедураларның нәтиҗәсе: Министрлыкка җибәрелгән гариза.

3.4.2. Лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында гаризагы һәм аңа теркәп тапшырыла торган документларны кабул итү, теркәү һәм бүлеккә җибәрү Регламентның 3.3.2 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.4.3. Бүлек белгече:

лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында гаризаның рәсмиләштерелүенең Регламентка 2 нче кушымтада күрсәтелгән, билгеләнгән формага туры китереп ярашлы булу-булмавын тикшерә;

Регламентның 2.5 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән, тапшырылган документлар пакеты составының тулылыгын тикшерә;

Дәүләт һәм муниципаль түләүләр турындагы дәүләт мәгълүмат системасында дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасының түләнгән булу-булмавын тикшерә;

тапшырылган документларны тикшерә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен Регламентның 2.7 пунктында каралган нигезләр булуын (булмавын) билгели.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен Регламентның 2.7 пунктындагы 3, 4, 6 пунктчаларында каралган нигезләр ачыкланган очракта, бүлек белгече сәбәпләрен күрсәтеп, документларны кабул итүдән баш тарту турында белдерү әзерли (Регламентка 9 нчы кушымта), лицензиатка (мөрәҗәгать итүчегә) аны тап-

шыра яисә, лицензиат (мөрәҗәгать итүче) ихтыярына карап, лицензияләүче органның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә, мондый белдерүнең җиткерелүен һәм лицензиат (мөрәҗәгать итүче) тарафыннан алынуын раслый торган ысул белән, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы итеп җибәрә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктындагы 1, 2 пунктчаларында каралган нигезләр ачыкланган очракта, бүлек белгече лицензиатка ачыкланган җитешсезлекләрне утыз көн эчендә бетерү кирәклеге һәм (яки) җитешеп бетмәгән документларны тапшыру зарурлыгы турында белдерү (Регламентка 6 нчы кушымта) тапшыра яки мондый белдерүне, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы белән җибәрә яисә лицензияләүче органның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ формасында җибәрә. Лицензиат тарафыннан, белдерүне алган вакыттан башлап, лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында тиешенчә рәсмиләштерелгән гариза һәм (яки) аңа теркәп тапшырыла торган документлар утыз көнлек срокта тулы күләмдә тапшырылмаган очракта, лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында элек тапшырылган гариза һәм аңа теркәп тапшырыла торган документлар лицензиатка кире кайтарылырга тиеш.

Регламентның 2.7 пунктындагы 1, 2, 3, 4, 6 пунктларындагы документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булмаса, бүлек белгече планнан тыш документар тикшерү үткәрү турында боерык әзерли.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаган көннән соңгы бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: планнан тыш документар тикшерү үткәрү турында боерык яисә ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү һәм (яки) булмаган документларны тапшыру зарурлыгы турында белдерү, лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында тапшырылган гаризаны һәм аңа теркәп бирелә торган документларны кире кайтару турында белдерү (Регламентка 8 нче кушымта), документларны кабул итүдән баш тарту турында белдерү.

Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы, ягъни лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү яисә аны үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында карар кабул итү вакыты лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында тиешенчә рәсмиләштерелгән гариза һәм аңа теркәп тапшырыла торган документлар тулы күләмендә Министрлыкка кергән көннән исәпләнә башлый.

3.4.4. Бүлек белгече Регламентның 3.3.4 - 3.3.6 пунктлары нигезендә планнан тыш документар тикшерү үткәрә.

3.4.5. Лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, Регламентның 3.3.7-3.3.9 пунктларында каралган процедуралар гамәлгә ашырыла.

3.4.6. Планнан тыш тикшерү үткәрү кирәк булган очракта, Регламентның 3.3.10-3.3.12 пунктларында каралган процедуралар гамәлгә ашырыла.

3.4.7. Лицензиатның лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урынында лицензия таләпләрен үтәү мөмкинлеге булмаган очракта, ул тикшерү актында чагылдырыла, Регламентның 3.3.7-3.3.9 пунктларында каралган процедуралар гамәлгә ашырыла.

3.4.8. Лицензиат тарафыннан лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урынында лицензия таләпләрен үтәү мөмкинлегенең булуы билгеләнгән очракта, ул тикшерү актында чагылдырыла, Регламентның 3.3.14-3.3.17 пунктларында каралган процедуралар гамәлгә ашырыла.

3.5. Лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү (юридик затны үзгәртеп кору, аның атамасын үзгәртү, урнашкан урынын үзгәртү рәвешендә юридик зат үзгәртеп корылган очракларда, шулай ук шәхси эшкуарның яшәгән урыны, исеме, фамилиясе һәм (булган очракта) атасының исеме, аның шәхесен таныклый торган документ реквизитлары үзгәртелгәндә, лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урыннарының аерым адреслары буенча эшчәнлек туктатылган очракларда).

3.5.1. Гариза Министрлыкка шәхсән, ышанычлы зат аша, почта буенча, Бердәм портал, Республика порталы, күпфункцияле үзәк аша тапшырылырга мөмкин.

Гариза һәм аңа теркәп тапшырыла торган документларны мөрәҗәгать итүче эшчәнлек башкару бүлегенә турыдан-туры кәгазьдә тапшырырга яисә, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы итеп җибәрергә хокуклы.

Лицензиат лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гаризаны һәм Регламентның 2.5 пунктының 3 пунктчасы нигезендә аңа теркәп тапшырыла торган документларны, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, электрон документлар (электрон документлар пакеты) рәвешендә җибәрә.

Гаризаны күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны аша тапшырган очракта, күпфункцияле үзәкнең гаризаларны кабул итә торган белгече:

гариза белән документларны кабул итә;

гаризаны терки;

гариза тутыруның тулылыгын һәм дөреслеген тикшерә;

лицензия алырга теләүчегә, лицензиатка гариза җибәрү датасы турында хәбәр итә;

документлар пакетын формалаштыра һәм аны күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән тәртиптә аны Министрлыкка җибәрә.

Регламентның әлеге пунктында билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә гамәлгә ашырыла: гариза Министрлыкка, Бердәм портал, Республика порталы аша тапшырылган очракта, мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне; гаризаны күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны аша тапшырган очракта, күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән срокларда.

Процедураларның нәтиҗәсе: Министрлыкка җибәрелгән гариза.

3.5.2. Лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында гаризагы һәм аңа теркәп тапшырыла торган документларны кабул итү, теркәү һәм бүлеккә җибәрү Регламентның 3.3.2 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.5.3. Бүлек белгече:

лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында гаризаның рәсмиләштерелүенең Регламентка 2 нче кушымтада күрсәтелгән, билгеләнгән формага туры китереп ярашлы булу-булмавын тикшерә;

Регламентның 2.5 пунктының 3 пунктчасында күрсәтелгән, тапшырылган документлар пакеты составының тулылыгын тикшерә;

Дәүләт һәм муниципаль түләүләр турындагы дәүләт мәгълүмат системасында дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасының түләнгән булу-булмавын тикшерә;

тапшырылган документларны тикшерә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен Регламентның 2.7 пунктында каралган нигезләр булуын (булмавын) билгели.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен Регламентның 2.7 пунктындагы 3, 4, 6 пунктчаларында каралган нигезләр ачыкланган очракта, бүлек белгече сәбәпләрен күрсәтеп, документларны кабул итүдән баш тарту турында белдерү әзерли (Регламентка 9 нчы кушымта), лицензиатка (мөрәҗәгать итүчегә) аны тапшыра яисә, лицензиат (мөрәҗәгать итүче) ихтыярына карап, лицензияләүче органның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә, мондый белдерүнең җиткерелүен һәм лицензиат (мөрәҗәгать итүче) тарафыннан алынуын раслый торган ысул белән, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы итеп җибәрә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктындагы 1, 2 пунктчаларында каралган нигезләр ачыкланган очракта, бүлек белгече лицензиатка ачыкланган җитешсезлекләрне утыз көн эчендә бетерү кирәклеге һәм (яки) җитешеп бетмәгән документларны тапшыру зарурлыгы турында белдерү (Регламентка 6 нчы кушымта) тапшыра яки мондый белдерүне, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы белән җибәрә яисә лицензияләүче органның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ формасында җибәрә. Лицензиат тарафыннан, белдерүне алган вакыттан башлап, лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында тиешенчә рәсмиләштерелгән гариза һәм (яки) аңа теркәп тапшырыла торган документлар утыз көнлек срокта тулы күләмдә тапшырылмаган очракта, лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында элек тапшырылган гариза һәм аңа теркәп тапшырыла торган документлар лицензиатка кире кайтарылырга тиеш.

Регламентның 2.7 пунктындагы 1, 2, 3, 4, 6 пунктларындагы документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булмаса, бүлек белгече планнан тыш документар тикшерү үткәрү турында боерык әзерли.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Регламентның 3.5.2 пунктында каралган процедураны тәмамлау көненнән соңгы бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: планнан тыш документар тикшерү үткәрү турында боерык яисә ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү һәм (яки) булмаган документларны тапшыру зарурлыгы турында белдерү, лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында тапшырылган гаризаны һәм аңа теркәп бирелә торган документларны кире кайтару турында белдерү (Регламентка 8 нче кушымта), документларны кабул итүдән баш тарту турында белдерү.

Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы, ягъни лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү яисә аны үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында карар кабул итү вакыты лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында тиешенчә рәсмиләштерелгән гариза

һәм аңа теркәп тапшырыла торган документлар тулы күләмендә Министрлыкка кергән көннән исәпләнә башлый.

3.5.4. Бүлек белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон рәвештә гарызнамәләр җибәрә:

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яисә Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә бирү турында – Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Регламентның 3.5.2 пунктында каралган процедураны тәмамлау көненнән соңгы бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.5.5. Белешмәләр белән тәэмин итүче белгечләр ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә сорала торган документларны (мәгълүматны) бирә яисә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документның һәм (яисә) мәгълүматның булмавы турында хәбәр (алга таба – документның һәм (яисә) мәгълүматның булмавы турында хәбәр) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар, законнарда билгеләнгән срокларда җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә мәгълүмат белән тәэмин итүче зат тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлеккә җибәрелгән документлар (мәгълүматлар) яки баш тарту турында белдерү.

3.5.6. Бүлек белгече Административ регламентның контрольлек таләпләре нигезендә планнан тыш документар тикшерү үткәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Регламентның 3.5.3 пунктында каралган процедура тәмамланган көннән соңгы биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерүгә юнәлдерелгән тикшерү акты, документлар проектлары.

3.5.7. Лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турындагы боерыкны әзерләү, имзалау, лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында лицензияләр реестрына язу кертү, лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында белдерү (Регламентка 11 нче кушымта), лицензияләр реестрыннан өземтә җибәрү Регламентның 3.3.14-3.3.17 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

### 3.6. Лицензиянең гамәлдә булуын туктату.

3.6.1. Гариза Министрлыкка шәхсән, ышанычлы зат аша, почта буенча, Бердәм портал, Республика порталы, күпфункцияле үзәк аша тапшырылырга мөмкин.

Лицензиат кәгазьдә яисә кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы итеп почта, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон докумен формасында лицензиянең гамәлдә булуын туктату турындагы гаризаны эшчәнлек башкару бүлегенә тапшыра (җибәрә).

Гаризаны күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны аша тапшырган очракта, күпфункцияле үзәкнең гаризаларны кабул итә торган белгече:

гариза белән документларны кабул итә;

гаризаны терки;

гариза тутыруның тулылыгын һәм дөреслеген тикшерә;

лицензия алырга теләүчегә, лицензиатка гариза җибәрү датасы турында хәбәр итә;

документлар пакетын формалаштыра һәм аны күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән тәртиптә аны Министрлыкка җибәрә.

Регламентның әлеге пунктында билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә гамәлгә ашырыла: гариза Министрлыкка, Бердәм портал, Республика порталы аша тапшырылган очракта, мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне; гаризаны күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны аша тапшырган очракта, күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән срокларда.

Процедураларның нәтиҗәсе: Министрлыкка җибәрелгән гариза.

3.6.2. Эшчәнлек башкару бүлеге белгече:

лицензиянең гамәлдә булуын туктату турындагы гаризаны кабул итә, Электрон Хөкүмәттә терки;

лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында гаризаны бүлеккә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында теркәлгән, бүлеккә карап тикшерүгә җибәрелгән гариза.

3.6.3. Бүлек белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон рәвештә гарызнамәләр җибәрә:

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яисә Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә бирү турында – Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаган көннән соңгы бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.6.4. Белешмәләр белән тәэмин итүче белгечләр ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә сорала торган документларны (мәгълүматны) бирә яисә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документның һәм (яисә) мәгълүматның булмавы турында хәбәр (алга таба – документның һәм (яисә) мәгълүматның булмавы турында хәбәр) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар, законнарда билгеләнгән срокларда җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә мәгълүмат белән тәэмин итүче зат тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлеккә җибәрелгән документлар (мәгълүматлар) яки баш тарту турында белдерү.

3.6.5. Бүлек белгече:

әлеге Регламентка 3 нче кушымтада күрсәтелгән, билгеләнгән формалы лицензиянең гамәлдә булуын туктату турындагы гаризаны рәсмиләштерүнең ярашлылыгын тикшерә;

тапшырылган гаризаны тикшерә һәм аны кабул итүдән баш тарту өчен Регламентның 2.7 пунктында каралган нигезләр булуын (булмавын) билгели.

Гаризаны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктындагы 1, 3, 6 пунктчаларында каралган нигезләр ачыкланган очракта, бүлек белгече сәбәпләрен күрсәтеп, документларны кабул итүдән баш тарту турында белдерү әзерли (Регламентка 9 нчы кушымта), лицензиатка (мөрәҗәгать итүчегә) аны тапшыра яисә, лицензиат (мөрәҗәгать итүче) ихтыярына карап, лицензияләүче органның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә, мондый белдерүнең җиткерелүен һәм лицензиат (мөрәҗәгать итүче) тарафыннан алынуын раслый торган ысул белән, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы итеп җибәрә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктындагы 1, 3, 6 пунктчаларында күрсәтелгән нигезләр булмаса, бүлек белгече лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында боерык проекты әзерли һәм аны килештерү өчен бүлек җитәкчесенә, юридик бүлек җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Регламентның 3.6.3 пунктында каралган процедураны тәмамлау көненнән соңгы бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында боерык проекты, документларны кабул итүдән баш тарту турында белдерү.

3.6.6. Бүлек җитәкчесе, юридик бүлек җитәкчесе лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында боерык проектын килештерә, ул министр урынбасарына имзалау өчен җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаган көннән соңгы бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: министр урынбасарына имзалау өчен җибәрелгән лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында килештерелгән боерык проекты.

3.6.7. Министр урынбасары лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында боерыкны имзалый һәм бүлек белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаган көннән соңгы бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында имзаланган боерык.

3.6.8. Бүлек белгече, лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында имзаланган боерык нигезендә, лицензиянең гамәлдә булуын туктату турындагы язуны лицензияләр реестрына кертә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура лицензиянең гамәлдә булуын туктату турындагы боерык имзаланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензияләр реестрына кертелгән лицензиянең гамәлдә булуын туктату турындагы язу.

3.6.9. Бүлек белгече лицензиатка, аның ихтыярына карап, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында яки, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы белән кәгазьдә лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында язмача белдерү (Регламентка 14 нче кушымта) җибәрә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү өчен күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткән очракта, күпфункцияле үзәк хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазьдә бирә.

Мөрәҗәгать итүче Бердәм портал, Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган электрон документ, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланып, шәхси кабинетка автомат җибәрелә.

Лицензиянең гамәлдә булуын туктату турындагы гаризада лицензиат электрон документ формасында лицензияләр реестрыннан өземтә алу зарурлыгына күрсәткән булса, лицензияләүче орган, лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында белдерү җибәрү белән бер үк вакытта, лицензияләр реестрыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган, электрон документ формасындагы өземтәне дә лицензиатка җибәрә.

Лицензиянең гамәлдә булу вакытын туктату турындагы гаризада лицензиат лицензияләр реестрыннан кәгазьдә өземтә алу зарурлыгына күрсәткән булса, лицензияләүче орган, лицензиянең гамәлдә булуын туктату турындагы белдерүне җибәрү белән бер үк вакытта, кулга тапшыру турында белдереп, лицензиатка заказлы почта юлламасы итеп лицензияләр реестрыннан өземтә дә җиткерә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура Регламентның 3.6.7 пунктында каралган процедураны тәмамлаган көннән соңгы өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында белдерү, лицензияләр реестрыннан өземтә (кирәк булган очракта).

## 3.7. Лицензияләр реестрыннан белешмәләр бирү.

3.7.1. Гариза Министрлыкка шәхсән, ышанычлы зат аша, почта буенча, Бердәм портал, Республика порталы, күпфункцияле үзәк аша тапшырылырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүче кәгазьдә яисә кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы итеп почта аша, яисә гади электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында лицензияләр реестрыннан конкрет лицензиат турында белешмәләр бирү турындагы гаризаны эшчәнлек башкару бүлегенә тапшыра (җибәрә).

Гаризаны күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны аша тапшырган очракта, күпфункцияле үзәкнең гаризаларны кабул итә торган белгече:

гариза белән документларны кабул итә;

гаризаны терки;

гариза тутыруның тулылыгын һәм дөреслеген тикшерә;

гариза җибәрү датасы турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итә;

документлар пакетын формалаштыра һәм аны күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән тәртиптә аны Министрлыкка җибәрә.

Регламентның әлеге пунктында билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә гамәлгә ашырыла: гариза Министрлыкка, Бердәм портал, Республика порталы аша тапшырылган очракта, мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне; гаризаны

күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны аша тапшырган очракта, күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән срокларда.

Процедураларның нәтиҗәсе: Министрлыкка җибәрелгән гариза.

3.7.2. Эшчәнлек башкару бүлеге белгече:

лицензияләр реестрыннан белешмәләр бирү турында гаризаны кабул итә, Электрон Хөкүмәттә терки;

лицензияләр реестрыннан белешмәләр бирү турындагы гаризаны бүлеккә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар лицензияләр реестрыннан белешмәләр бирү турында гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: лицензияләр реестрыннан белешмәләр бирү турында теркәлгән, бүлеккә карап тикшерү өчен җибәрелгән гариза.

3.7.3. Бүлек белгече:

лицензияләр реестрыннан белешмәләр бирү турында гариза рәсмиләштерүнең Регламентка 4 нче кушымтада күрсәтелгән, билгеләнгән формага туры килү-килмәвен тикшерә;

Дәүләт һәм муниципаль түләүләр турындагы дәүләт мәгълүмат системасында лицензияләр реестрыннан кәгазьдә өземтә биргән өчен түләнгәнлек турында белешмәләр булу-булмавын тикшерә;

тапшырылган документларны тикшерә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен Регламентның 2.7 пунктында каралган нигезләр булуын (булмавын) билгели.

Гаризаны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктындагы 1, 5, 6 пунктчаларында каралган нигезләр ачыкланган очракта, бүлек белгече сәбәпләрен күрсәтеп, документларны кабул итүдән баш тарту турында белдерү әзерли (Регламентка 9 нчы кушымта), мөрәҗәгать итүчегә аны тапшыра яисә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап, бүлек белгече көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә, мондый белдерүнең җиткерелүен һәм мөрәҗәгать итүче тарафыннан алынуын раслый торган ысул белән, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы итеп җибәрә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 1, 5, 6 пунктларында күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта, бүлек белгече конкрет лицензия турында лицензияләр реестрыннан өземтә әзерли яисә кабул ителгән карар турында Министрлык акты күчермәсен, яисә сорала торган белешмәләрнең белмавы турында, лицензияләр реестрында лицензияләр турында белешмәләр булмаганда яки конкрет лицензиатны билгеләү мөмкинлеге булмаганда бирелә торган белешмә әзерли.

Лицензияләр реестрыннан электрон документ рәвешендә бирелә торган өземтә бүлек белгеченең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаган көннән соңгы ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: конкрет лицензия турында лицензияләр реестрыннан өземтә, яисә кабул ителгән карар турында Министрлык акты күчермәсе, яки сорала торган белешмәләрнең булмавы турында белешмә, документларны кабул итүдән баш тарту турында белдерү.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү өчен күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткән очракта, күпфункцияле үзәк хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазьдә бирә.

Конкрет лицензия турында белешмәләр шулай ук, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап, аңа турыдан-туры тапшырыла, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы итеп җибәрелә яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, лицензияләр реестрыннан өземтә рәвешендә, яисә кабул ителгән карар турында лицензияләүче орган актының күчермәсе, яисә сорала торган белешмәләрнең булмавы турында белешмә рәвешендә җибәрелә.

### 3.8. Техник хаталарны төзәтү.

3.8.1. Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Бүлеккә түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (Регламентка 15  нче кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак тапшырылган, техник хатасы булган документ;

техник хатаның булуын таныклаучы документлар.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдә техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры кәгазьдә тапшырыла яки почта аша, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы итеп яисә Бердәм портал, Республика порталы яки күпфункцияле үзәк аша җибәрелә.

3.8.2. Министрлыкның эшчәнлек башкару бүлеге белгече техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә, кушымта итеп бирелгән документлары белән гаризаны терки һәм аларны бүлеккә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәү көненнән соңгы бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, бүлек белгеченә карап тикшерүгә җибәрелгән гариза.

3.8.3. Бүлек белгече документларны карый һәм хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатларында, мөрәҗәгать итүчегә төзәтелгән документны шәхсән имзалап тапшыра яки мөрәҗәгать итүче адресына почта юлламасы итеп җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланган вакыттан башлап яисә җибәрелгән хата турында теләсә кайсы мәнфәгатьле заттан гариза алынганнан соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган (җибәрелгән) документ.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләр үтәлешен һәм башкарылуын даими тикшереүдә тоту дәүләт хезмәте күрсәтү эшен оештыру өчен җаваплы министр (министр урынбасары) тарафыннан башкарыла.

4.2. Агымдагы контрольлек Министрлыктагы вазыйфаи затларның Регламентта һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвенә һәм башкаруына тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре түбәндәгеләргә карата тикшерүләр уздырудан гыйбарәт:

эшнең алып барылуына;

документларны карап тикшерү нәтиҗәләренең законнардагы (Регламенттагы) таләпләргә туры килү-килмәвенә;

документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр бирү сроклары һәм тәртибе үтәлешенә.

4.3. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәсендә дәүләт хезмәтен башкарганда Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан җибәрелгән хокук бозу очраклары ачыкланган очракта, гаепле затлар закон нигезендә дисциплинар җаваплылыкка тартыла.

4.4. Регламент үтәлешенә гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар тарафыннан контрольдә тоту Министрлыкка мөрәҗәгатьләр җибәрү юлы белән, шулай ук Регламентны үтәү барышында гамәлгә ашырыла торган (кабул ителгән) гамәлләргә (гамәл кылмауны) һәм карарларга югары торучы дәүләт хакимияте органнарына шикаять белдерү юлы белән дә гамәлгә ашырыла.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшерү Министрлык актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Тикшерүләр планлы (Министрлыкның яртыеллык яисә еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган) һәм планнан тыш булырга мөмкин.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты яисә Министрлыкның дәүләт граждан хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә Министрлыкка шикаять белдерергә хокуклы. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә министр тарафыннан кабул ителгән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелә.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр күпфункцияле үзәк җитәкчесенә белдерелә, күпфункцияле үзәк

җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) – күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы затка.

210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясындагы $1^1$ өлешендә каралган оешмаларның хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр әлеге оешмалар җитәкчеләренә тапшырыла.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатен, 210-ФЗ номерлы Федераль законның $15^1$ статьясында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгатьне теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда. Әлеге очракта, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы $1^3$ өлешендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт хезмәтләрен тулы күләмендә күрсәтү функциясе йөкләнгән булса, мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять, карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата күпфункцияле үзәккә шикаять белдерелә ала;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартылганда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса. Әлеге очракта, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы $1^3$ өлешендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт хезмәтләрен тулы күләмендә күрсәтү функциясе йөкләнгән булса, мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять, карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата күпфункцияле үзәккә шикаять белдерелә ала;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы $1^1$ өлешендә каралган оешмалар яисә аларның хезмәткәрләре дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән срогы бозылганда; Әлеге очракта, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы $1^3$ өлешендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт хез-

мәтләрен тулы күләмендә күрсәтү функциясе йөкләнгән булса, мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять, карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата күпфункцияле үзәккә шикаять белдерелә ала;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтү туктатып торылганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында туктатып тору нигезләре каралмаган булса. Әлеге очракта, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясындагы $1^3$ өлешендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт хезмәтләрен тулы күләмендә күрсәтү функциясе йөкләнгән булса, мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата күпфункцияле үзәккә шикаять белдерелә ала;

10) мөрәҗәгать итүчедән, күрсәтелгән вакытта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп ителгәндә. Әлеге очракта, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы $1^3$ өлешендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт хезмәтләрен тулы күләмендә күрсәтү функциясе йөкләнгән булса, мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять, карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата күпфункцияле үзәккә шикаять белдерелә ала.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта буенча, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» челтәрен, Министрлыкның рәсми сайтын, Бердәм порталны яисә Республика порталын кулланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү вакытында да алынырга мөмкин.

Күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять почта буенча, "Интернет" челтәреннән, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайтыннан, Бердәм порталдан яки Республика порталыннан файдаланып җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү вакытында да алынырга мөмкин.

210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы $1^1$ өлешендә каралган оешмаларның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почта аша, «Интернет» челтәрен, әлеге оешмаларның рәсми сайтларын, Бердәм порталны яисә Республика порталын кулланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхси кабул итү вакытында да кабул итеп алынырга мөмкин.

5.4. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карап тикшерү чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә.

Министрлыкның, күпфункцияле үзәкнең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1[1] өлешендә каралган оешмаларның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән яисә хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгән очракта яки мондый төзәтмәләрне кертү чоры бозылганда, – аны теркәгән көннән башлап биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган Министрлыкның, Министрлык вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең һәм (яки) 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1[1] өлешендә каралган оешмалар хезмәткәренең, аларның җитәкчеләренең һәм (яки) хезмәткәрләренең исемнәре;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) Министрлыкның, Министрлык вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең һәм (яки) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1[1] өлешендә каралган оешмалар хезмәткәренең, аларның җитәкчеләренең һәм (яки) хезмәткәрләренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүче Министрлыкның, Министрлык вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең һәм (яки) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1[1] өлешендә каралган оешмалар хезмәткәренең, аларның җитәкчеләренең һәм (яки) хезмәткәрләренең карары һәм гамәле (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезли торган белешмәләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы көннән соңга калмыйча, Мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә, аның ихтыяры буенча, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, әлеге Регламентның 5.6 пунктында күрсәтелгән җавапта мөрәҗәгать итүчегә, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максат-ларында, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк яисә 210-ФЗ номерлы

Федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешма тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм, дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында, алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиешле түгел дип танылган очракта, әлеге Регламентның 5.6 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

Кара металл, төсле металл ватыклары әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Форма

Кара металл, төсле металл ватыклары әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өчен лицензия бирү турында
ГАРИЗА

Сездән ___________________________________________________________
(тулы һәм (булган очракта) кыскартылган атама, шул исәптән фирма исеме, һәм оешу-хокук формасы – юридик зат өчен; фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта), шәхес таныклый торган документ белешмәләре – шәхси эшкуар өчен)

кара металл, төсле металл ватыклары әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өчен лицензия бирүегез турында үтенәм
лицензияләнә торган эшчәнлек төре составында башкарыла торган эш төрен (төрләрен) сайларга:

☐ кара металл ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату

☐ төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату

☐ төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, сату

Юридик зат урнашкан урын (шәхси эшкуар яшәгән урын адресы) ____________________________
_____________________________________________________________________________

Язышу адресы ___________________________________________________________
(почта адресы, электрон почта адресы, элемтә өчен телефон)

Лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урыннарының адреслары _____________
_____________________________________________________________________________

Дәүләт теркәвенә алу турындагы язуың төп дәүләт теркәү номеры _____________________
_____________________________________________________________________________
(ОГРН – юридик зат өчен, ОГРНИП – шәхси эшкуар өчен)

Юридик затларның (шәхси эшкуарның) бердәм дәүләт реестрына мәгълүматлар кертү фактын раслаучы документ белешмәләре _________________________________________________

Салым түләүченең тәңгәллек номеры (ИНН)______________________________________

Юридик затны (шәхси эшкуарны) салым органында исәпкә кую фактын раслый торган документ белешмәләре____________________________________________________________
Лицензияләнә торган эшчәнлек алып бару өчен кирәкле һәм милек хокукында яки башка законлы нигездә юридик затка (шәхси эшкуарга) караган, аларга карата хокуклар Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында теркәлгән җир кишәрлекләре, биналар, төзелмәләр, корылмалар һәм бүлмәләр (биналарның, төзелмәләрнең, корылмаларның һәм бүлмәләрнең бердәм аерымланган өлеше) турында белешмәләр _______________________________________________
_____________________________________________________________________________

Лицензияләү мәсьәләләре буенча вәкаләтле хезмәткәр________________________________________

(вазыйфа атамасы, фамилия, исем, ата исеме
(соңгысы – булган очракта), телефон)

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының кара металл, төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өчен лицензияләр реестрыннан өземтә бирү кирәклеге турында белешмәләр

☐ реестрдан өземтә кирәк (формасын сайларга**)**:

☐ кәгазьдә (лицензияләр реестрыннан өземтә югарыда күрсәтелгән почта адресы буенча җибәрелә)

☐ электрон документ формасында (бары тик гариза электрон документ формасында бирелгән очракта гына)

☐ лицензияләр реестрыннан өземтә кирәкми

(«Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы нигезендә, лицензияләр реестрыннан кәгазь күчермә лицензияләүче органның көчәйтелгән квалифицияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә түләү алмыйча бирелә.)

Юридик зат җитәкчесе
(шәхси эшкуар) ____________________ ______________________________

(имза,мөһер) (Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта))

Искәрмә. Мөһер – булган очракта

Имзалаган көннән башлап язмача формада кайтарып алган көнгә кадәр персональ белешмәләрне эшкәртүгә риза (шәхси эшкуарлар өчен)____________________________________________

(Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта))

Кара металл, төсле металл ватыклары әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Форма

Лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында
ГАРИЗА
(юридик зат яисә шәхси эшкуар тарафыннан лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урыннары адресларын, эшчәнлекнең лицензияләнә торган төрен тәшкил итүче башкарыла торган эшләр исемлеге үзгәртелгәндә, юридик затны үзгәртеп кору, аның атамасын үзгәртү, урнашкан урынын үзгәртү рәвешендә юридик затны үзгәртү очракларында, шулай ук шәхси эшкуарның исеме, фамилиясе һәм (булган очракта) атасының исеме, шәхесен раслый торган документ реквизитлары, лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урыннарының аерым адреслары буенча эшчәнлек туктатылган очракларда)

Сездән түбәндәгене үзгәртеп рәсмиләштерүегез турында үтенәм ______________________________
______________________________________________________________________________
(тулы һәм (булган очракта) кыскартылган атама, шул исәптән фирма исеме, һәм оешу-хокук формасы – юридик зат өчен;
фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта), шәхес таныклый торган документ белешмәләре – шәхси эшкуар өчен)

лицензия ______________________________________________________________________
(лицензиянең теркәү номеры һәм лицензия бирү датасы)

кара металл, төсле металл ватыклары әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өчен

лицензияләнә торган эшчәнлек төре составында башкарыла торган эш төрен (төрләрен) сайларга:

☐ кара металл ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату

☐ төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату

☐ төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, сату

чөнки __________________________________________________________________________

Юридик зат урнашкан урын (шәхси эшкуар яшәгән урын адресы) ____________________________

Язылышу адресы _____________________________________________________________
(почта адресы, электрон почта адресы, элемтә өчен телефон)

Лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урыннарының адреслары ______________
______________________________________________________________________________

Дәүләт теркәвенә алу турындагы язуның төп дәүләт теркәү номеры ________________________
______________________________________________________________________________
(ОГРН – юридик зат өчен, ОГРНИП – шәхси эшкуар өчен)

Юридик затларның (шәхси эшкуарның) бердәм дәүләт реестрына мәгълүматлар кертү фактын раслаучы документ белешмәләре ________________________________________

Салым түләүченең тәңгәллек номеры (ИНН)__________________________________________

Юридик затны (шәхси эшкуарны) салым органында исәпкә кую фактын раслый торган документ белешмәләре _______________________________________________

Лицензияләнә торган эшчәнлек алып бару өчен кирәкле һәм милек хокукында яки башка законлы нигездә юридик затка (шәхси эшкуарга) караган, аларга карата хокуклар Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында теркәлгән җир кишәрлекләре, бипалар, төзелмәләр, корылмалар һәм бүлмәләр (биналарның, төзелмәләрнең, корылмаларның һәм бүлмәләрнең бердәм аерымланган өлеше) турында белешмәләр _____________________________________________________________

Лицензияләү мәсьәләләре буенча вәкаләтле хезмәткәр_____________________________________

(вазыйфа атамасы, фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта), телефон)

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының кара металл, төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өчен лицензияләр реестрыннан өземтә бирү кирәклеге турында белешмәләр

☐ реестрдан өземтә кирәк **(**формасын сайларга**):**

☐ кәгазьдә (лицензияләр реестрыннан өземтә югарыда күрсәтелгән почта адресы буенча җибәрелә)

☐ электрон документ формасында (бары тик гариза электрон документ формасында бирелгән очракта гына)

☐ лицензияләр реестрыннан өземтә кирәкми

(«Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы нигезендә, лицензияләр реестрыннан кәгазь күчермә лицензияләүче органның көчәйтелгән квалифицияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә түләү алмыйча бирелә.)

Юридик зат җитәкчесе
(шәхси эшкуар) _______________________ ___________________________
(имза,мөһер) (Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта))
Искәрмә. Мөһер – булган очракта

Имзалаган көннән башлап язмача формада кайтарып алган көнгә кадәр персональ белешмәләрне эшкәртүгә риза (шәхси эшкуарлар өчен)__________________________________________________
(Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта))

Кара металл, төсле металл ватыклары әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Форма

Лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында
ГАРИЗА

Лицензиянең гамәлдә булуын туктатуыгыз турында үтенәм ___________________________________
(лицензиянең теркәү номеры һәм лицензия бирү датасы)

кара металл, төсле металл ватыклары әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өчен

Юридик затның (шәхси эшкуарның) исеме ___________________________________________

Юридик зат урнашкан урын (шәхси эшкуар яшәгән урын адресы) ___________________________

Язылышу адресы _____________________________________________________________________
(почта адресы, электрон почта адресы, элемтә өчен телефон)

Дәүләт теркәвенә алу турындагы язуның төп дәүләт теркәү номеры
______________________________________________________________________________________
(ОГРН – юридик зат өчен, ОГРНИП – шәхси эшкуар өчен)

Юридик затларның (шәхси эшкуарның) бердәм дәүләт реестрына мәгълүматлар кертү фактын раслаучы документ белешмәләре _______________________________________________________

Салым түләүченең тәңгәллек номеры (ИНН)___________________________________________

Юридик затны (шәхси эшкуарны) салым органында исәпкә кую фактын раслый торган документ белешмәләре_____________________________________________________________________

Лицензияләү мәсьәләләре буенча вәкаләтле хезмәткәр_______________________________
(вазыйфа атамасы, фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта), телефон)

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының кара металл, төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өчен лицензияләр реестрыннан өземтә бирү кирәклеге турында белешмәләр

☐ реестрдан өземтә кирәк **(**формасын сайларга**):**

☐ кәгазьдә ____________________________________________________
(почта адресын күрсәтергә)

☐ электрон документ формасында (бары тик гариза электрон документ формасында бирелгән очракта гына)

☐ лицензияләр реестрыннан өземтә кирәкми

(«Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы нигезендә, лицензияләр реестрыннан кәгазь күчермә лицензияләүче органның көчәйтелгән квалифицияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә түләү алмыйча бирелә.)

Юридик зат җитәкчесе
(шәхси эшкуар) ________________________ ____________________________________
(имза, булган очракта – мөһер) (Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта))
Искәрмә. Мөһер – булган очракта

Имзалаган көннән башлап язмача формада кайтарып алган көнгә кадәр персональ белешмәләрне эшкәртүгә риза (шәхси эшкуарлар өчен)_____________________________________________________
(Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта))

Кара металл, төсле металл ватыклары әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

Форма

Лицензияләр реестрыннан белешмәләр бирү турында
ГАРИЗА

Лицензия турында мәгълүмат бирүегезне сорыйм____________________________________
(лицензиянең теркәү номерын һәм лицензия бирү датасын күрсәтергә)
Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының кара металл, төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өчен лицензияләр реестрыннан

Мөрәҗәгать итүче ____________________________________________________________
(тулы һәм (булган очракта) кыскартылган исеме – юридик зат өчен; фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булган очракта) – шәхси эшкуар, физик зат өчен.

Язышу адресы ________________________________________________________________
(почта адресы, электрон почта адресы, элемтә өчен телефон)

Лицензия турында мәгълүмат алу формасы һәм ысулы (кирәклесен билгеләргә):

☐ кәгазьдә______________________________________________________________
(почта адресын күрсәтергә)

☐ электрон документ формасында (бары тик гариза электрон документ формасында бирелгән очракта гына)

(«Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы нигезендә, лицензияләр реестрыннан кәгазь күчермә лицензияләүче органның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә түләү алмыйча бирелә.)

Мөрәҗәгать итүче __________________________________________ ___________________________
(имза, булган очракта – мөһер) (Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта))

Имзалаган көннән башлап язмача формада кайтарып алган көнгә кадәр персональ белешмәләрне эшкәртүгә риза (шәхси эшкуарлар, физик затлар өчен)__________________________________
(Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта))

Кара металл, төсле металл ватыклары әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

____________________________________
(юридик затның/шәхси эшкуарның исеме, ИНН, ОГРН/ОГРНИП)

**Ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү һәм (яки) булмаган документларны тапшыру зарурлыгы турында белдерү**

«Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 8 өлеше нигезендә, Сезгә ___________________ № __________ кара металл, төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өчен лицензия бирү турындагы гаризаның карауга кабул ителмәве турында хәбәр итәбез, чөнки ______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
(җитешсезлекләрне күрсәтергә)

«Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 9 өлеше нигезендә, гаризагызны кабул иткән көннән соң утыз көн эчендә ачыкланган җитешсезлекләрне бетергән очракта, Сезнең гариза каралуга кабул ителәчәк, югыйсә, утыз көнлек чор узып киткәч, _______ № _____ лицензия бирү турындагы гаризага теркәлгән документлар Сезгә кире кайтарылачак.

Министр урынбасары

________________________________
(Фамилия, исем, ата исеме)

Кара металл, төсле металл ватыклары әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 6 нчы кушымта

___________________________
(юридик затның/шәхси эшкуарның исеме, ИНН, ОГРН/ОГРНИП)

**Ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү һәм (яки) булмаган документларны тапшыру зарурлыгы турында белдерү**

«Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 12 өлеше нигезендә __________________ № ____
(лицензиянең теркәү номеры һәм лицензия бирү датасы)
кара металл, төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өчен лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турындагы гаризагыз каралуга кабул ителмәде, чөнки __________________
___________________________________________________________________________________________
(җитешсезлекләрне күрсәтергә)

«Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 14 өлеше нигезендә, гаризагызны кабул иткән көннән соң утыз көн эчендә ачыкланган җитешсезлекләрне бетергән очракта, Сезнең гариза каралуга кабул ителәчәк, югыйсә, утыз көнлек чор узып киткәч, _______ № _____ лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турындагы гаризага теркәлгән документлар Сезгә кире кайтарылачак.

Министр урынбасары ___________________________
(Фамилия, исем, ата исеме)

Кара металл, төсле металл ватыклары әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 7 нче кушымта

______________________________
(юридик затның/шәхси эшкуарның исеме, ИНН, ОГРН/ОГРНИП)

**Лицензия бирү турында тапшырылган гаризаны һәм аңа теркәп тапшырылган документларны кире кайтару турында белдерү**

«Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 8 өлеше нигезендә, ______ № ____ кара металл, төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өчен лицензия бирү турындагы гариза билгеләнгән форманы бозып рәсмиләштерелгән һәм (яки) документлар тулы күләмдә тапшырылмаган булу сәбәпле, Сезгә ачыкланган җитешсезлекләрне утыз көнлек чорда бетерү зарурлыгы һәм (яки) булмаган документларны тапшыру турында белдерү җибәрелде.

«Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 10 өлеше нигезендә, лицензия алырга теләүче зат ачыкланган җитешсезлекләрне утыз көнлек чорда бетерү зарурлыгы һәм (яки) булмаган документларны тапшыру турында белдерү алынганнан соң җитешсезлекләр бетерелмәсә һәм (яки) булмаган документлар, тиешенчә рәсмиләштерелгән лицензия бирү турындагы гариза һәм (яки) аңа теркәлә торган документлар тулы күләмендә тапшырылмаса, лицензия бирү турында элегрәк бирелгән гариза һәм аңа теркәп тапшырылган документлар лицензия алырга теләүче затка кире кайтарып бирелергә тиеш.

Билгеләнгән срокларда лицензия бирү турында тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән гариза һәм (яки) аңа беркетеп бирелә торган документлар тапшырылмаганга күрә, Сезнең тарафтан элегрәк тапшырылган______ № ____ лицензия бирү турындагы гариза һәм теркәп тапшырылган документлар кире кайтарыла.

Министр урынбасары

______________________________
(Фамилия, исем, ата исеме)

Кара металл, төсле металл ватыклары әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 8 нче кушымта

______________________________________

(юридик затның/шәхси эшкуарның исеме, ИНН, ОГРН/ОГРНИП)

**Лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында бирелгән гаризаны һәм аңа теркәп тапшырылган документларны кире кайтару турында белдерү**

«Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 12 өлеше нигезендә ______ № ____ кара металл, төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өчен лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турындагы гариза______________________________________________________________________
(лицензиянең теркәү номеры һәм лицензия бирү датасы)
билгеләнгән форманы бозып рәсмиләштерелгән һәм (яки) документлар тулы күләмдә тапшырылмаган булуы сәбәпле, Сезгә ачыкланган җитешсезлекләрне утыз көнлек чорда бетерү һәм (яки) булмаган документларны тапшыру зарурлыгы турында белдерү җибәрелде.

«Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 14 өлеше нигезендә, лицензиат ачыкланган җитешсезлекләрне утыз көнлек чорда бетерү зарурлыгы һәм (яки) булмаган документларны тапшыру турында белдерү алынганнан соң җитешсезлекләр бетерелмәсә һәм (яки) булмаган документлар, тиешенчә рәсмиләштерелгән лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турындагы гариза һәм (яки) аңа теркәлә торган документлар тулы күләмендә тапшырылмаса, лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында элегрәк бирелгән гариза һәм аңа теркәп тапшырылган документлар лицензиатка кире кайтарып бирелергә тиеш.

Билгеләнгән срокларда лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән гариза һәм (яки) аңа беркетеп бирелә торган документлар тапшырылмаганга күрә, Сезнең тарафтан элегрәк тапшырылган______ № ____ лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турындагы гариза һәм теркәп тапшырылган документлар кире кайтарыла.

Министр урынбасары ____________________________________

(Фамилия, исем, ата исеме)

Кара металл, төсле металл
ватыклары әзерләү, саклау,
эшкәртү һәм сату эшчәнлеген
лицензияләү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
9 нчы кушымта

___________________________________

Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта),
юридик затның/шәхси эшкуарның исеме, ИНН, ОГРН/ОГРНИП)

**Документларны кабул итүдән баш тарту турында белдерү**

«Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә _______________ № ____ гаризагыз _______________
____________________________________________________________________________
(нәрсәгә бәйле рәвештә гариза бирелә)
караугa кабул ителмәде, чөнки ___________________________________________.
(җитешсезлекләрне күрсәтергә)

Министр урынбасары ___________________________
(Фамилия, исем, ата исеме)

Кара металл, төсле металл
ватыклары әзерләү, саклау,
эшкәртү һәм сату эшчәнлеген
лицензияләү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
10 нчы кушымта

___________________________________
(юридик затның/шәхси эшкуарның исеме,
ИНН, ОГРН/ОГРНИП)

**Лицензия бирү турында белдерү**

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы «Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 5 өлеше нигезендә Сезнең ______ № ____ гаризагыз буенча Министрлыкның_____ № ____ боерыгы нигезендә кара металл, төсле металл ватыклары әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өчен ___________________________________ лицензия бирү турында карар кабул ителде, дип хәбәр итә
(лицензиянең теркәү номеры һәм лицензия бирү датасы)

Министр урынбасары ___________________________
(Фамилия, исем, ата исеме)

Кара металл, төсле металл ватыклары әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 11 нче кушымта

________________________________
(юридик затның/шәхси эшкуарның исеме, ИНН, ОГРН/ОГРНИП)

**Лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында белдерү**

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы «Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 18 өлеше нигезендә Сезнең ______ № ____ лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турындагы гаризагыз буенча ______________________________
(лицензиянең теркәү номеры һәм лицензия бирү датасы)
кара металл, төсле металл ватыклары әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өчен _________________________________________ __________________________________________,
(үзгәртеп рәсмиләштерүнең нәрсә белән бәйле булуын күрсәтергә)
Министрлыкның_____ № ____ боерыгы нигезендә лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында карар кабул ителде, дип хәбәр итә.

Министр урынбасары ___________________________
(Фамилия, исем, ата исеме)

Кара металл, төсле металл ватыклары әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 12 нче кушымта

___________________________
(юридик затның/шәхси эшкуарның исеме, ИНН, ОГРН/ОГРНИП)

**Лицензия бирүдән баш тарту турында белдерү**

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы______ № ____ кара металл, төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өчен лицензия бирү турындагы гаризагыз нигезендә Министрлыкның _____ № ____ боерыгы нигезендә, «Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 7 өлеше нигезендә лицензия бирүдән баш тарту турында карар кабул ителде, дип хәбәр итә.

Баш тарту нигезләре:
______________________________________________________________________

Министр урынбасары ___________________________
(Фамилия, исем, ата исеме)

Кара металл, төсле металл ватыклары әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 13 нче кушымта

______________________________
(юридик затның/шәхси эшкуарның исеме, ИНН, ОГРН/ОГРНИП)

**Лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында белдерү**

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы _______ № ______ лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турындагы гаризагыз буенча ______________________________
(лицензиянең теркәү номеры һәм лицензия бирү датасы)
кара металл, төсле металл ватыклары әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өчен ________________________________________ ________________________________________,
(үзгәртеп рәсмиләштерүнең нәрсә белән бәйле булуын күрсәтергә)
Министрлыкның_____ № ____ боерыгы нигезендә, «Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 7 өлеше нигезендә лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында карар кабул ителде, дип хәбәр итә.

Баш тарту нигезләре:
______________________________________________________________________

Министр урынбасары ______________________________
(Фамилия, исем, ата исеме)

Кара металл, төсле металл
ватыклары әзерләү, саклау,
эшкәртү һәм сату эшчәнлеген
лицензияләү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
14 нче кушымта

_______________________________
(юридик затның/шәхси эшкуарның исеме,
ИНН, ОГРН/ОГРНИП)

**Лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында белдерү**

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы «Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясы нигезендә Сезнең ____________ № ____ гаризагыз буенча Министрлыкның ___________ № _____ боерыгы белән кара металл, төсле металл ватыклары әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өчен лицензиянең 20 __ елның «____»______ башлап гамәлдән чыккан дип тану турында карар кабул итүе хакында хәбәр итә

____________________________________________________________________________
(лицензиянең теркәү номеры һәм лицензия бирү датасы)

Министр урынбасары _____________________________
(Фамилия, исем, ата исеме)

Кара металл, төсле металл ватыклары әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 15 нче кушымта

Техник хатаны төзәтү турында
ГАРИЗА

Кара металл, төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәткәндә җибәрелгән техник хатаны төзәтүегез турында сорыйм

Хатаны тасвирлау: ________________________________________________________________

Түбәндәге документларны терким:
1.
2.
3.

Лицензияләү мәсьәләләре буенча вәкаләтле хезмәткәр___________________________________
(вазыйфа атамасы, фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта), телефон)

Юридик зат җитәкчесе
(шәхси эшкуар) _______________________ __________________________
(имза,мөһер) (Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта))

Искәрмә. Мөһер – булган очракта

Имзалаган көннән башлап язмача формада кайтарып алган көнгә кадәр персональ белешмәләрне эшкәртүгә риза (шәхси эшкуарлар өчен)__________________________________________________
(Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта))

Кара металл, төсле металл
ватыклары әзерләү, саклау,
эшкәртү һәм сату эшчәнлеген
лицензияләү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
(белешмәлек) кушымта

Кара металл, төсле металл ватыклары әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы һәм аны күрсәтүне контрольдә тотучы органнар һәм вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 524-91-11 | me.rt@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 524-91-05 | Kondratova.Natalya @tatar.ru |
| Лицензияләү бүлеге җитәкчесе | 524-91-48 | Nadezhda.Gornovskaya @tatar.ru |
| Лицензияләү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе | 524-91-49 | L.Safin@tatar.ru |
| Лицензияләү бүлегенең әйдәп баручы белгече | 524-90-22 | Hasanova.Elmira@tatar.ru |
| Эшчәнлек башкару бүлеге җитәкчесе | 524-91-68 | Ramziya.Zimina@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Сәнәгать бүлеге җитәкчесе | 264-76-74 | German.Fashiev@tatar.ru |